# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 1** **26.11.2021**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге составына керүче, Бирючевка авылында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка торак пункты территориясендә, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту буенча үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

1. Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җину көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне»,"Авыл бәйрәме" нэ бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);
**2.** Бирючевка авыл җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру);
3. Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (үлән чабу эшләре өчен түләү(килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);
4. Карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен (тракторчыга), юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү, (ягулык-майлау материаллары

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бирючевка авыл җирлеге Башлыгы В.В.Крашенинников